| МИНИСТЕРСТВО ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО УПРАВЛЕНИЯ, ИНФОРМАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.05.2024 Казан ш. №п/102

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу тәртибе турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктының «б» пунктчасы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.
2. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге җитәкчесенә Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга.
3. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Эшкә алучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе турында» 24.07.2017 №8-05-п/134;

«Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Эшкә алучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә

коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе турында» 24.07.2017 №8-05-п/134 боерыгы белән расланган Эшкә алучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 28.05.2019 №8-05-п/201.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Дәүләт
идарәсен цифрлы нигездә үстерү,
мәгълүмат технологияләре һәм
элемтә министрлыгының 22.05.2024
№п/102 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – Министрлык, граждан хезмәткәре) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртип аларны эшкә яллаучы вәкиле булып Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) торган граждан хезмәткәрләренә кагыла.

Әлеге Тәртип сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән Министрлыкның беренчел һөнәри берлек оешмасының сайлап алу органы белән идарә итүдә граждан хезмәткәрләренең башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашу очракларына кагылмый.

3. Граждан хезмәткәренең коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр каршылыгына яки вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималына китермәскә тиеш.

4. Коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашу өчен рөхсәт алу граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә язма рәвештә гариза тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Граждан хезмәткәре Министрлыкның коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затына (алга таба – Җаваплы зат) коммерциясез оешма белән идарә итә башлаганчы гариза бирә.

6. Җаваплы зат гаризаны кергән көнендә шушы Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Журналда терки.

7. Теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә Җаваплы зат гаризаны карый һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны барышында Җаваплы зат гариза тапшырган граждан хезмәткәреннән коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуының планлаштырылган функцияләрен билгеләүче язмача аңлатмаларны һәм документларны сорарга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итү яки рөхсәт бирмәү турында тәкъдим булырга тиеш.

8. Җаваплы зат, гаризаны теркәгән көннән башлап җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, граждан хезмәткәренә коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен, бәяләмәне һәм башка материалларны (булган очракта) теркәп, гаризаны министрга тапшыра.

Министр Җаваплы заттан гариза алган көннән ике эш көне эчендә карар кабул итә.

Карар гаризага тиешле резолюция кертү юлы белән рәсмиләштерелә.

9. Җаваплы затн тарафыннан баш тарту тәкъдиме белән бәяләмә әзерләү өчен, шулай ук министр тарафыннан граждан хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып Тәртипнең 3 пунктында каралган шартларның килеп чыгуы тора.

10. Җаваплы зат министр тарафыннан карар кабул ителгән көннән соңгы ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа гаризаның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең мөһере белән таныкланган, министр резолюциясе куелган күчермәсен кул куйдыртып тапшыра.

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрына

______________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме, били торган

____________________________________
вазыйфа һәм структур бүлекчә,

______________________________________
яшәү урыны буенча адрес, телефон номеры)

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу турында гариза

Түбәндәге белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт бирүегез турында сорыйм ________________________________________________________________________
(оештыру-хокукый форма, атама, ИНН, адрес)
________________________________________________________________________.

______________________________________________сыйфатында түләүсез нигездә
(бердәнбер башкарма орган яки коллегиаль идарә органының исеме)
________________________________________________________________________.

________________ ____________ ________________________
(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| т/с | Теркәү көне | Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Гариза бирүченең имзасы | Җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Җаваплы затның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

---